СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт,
Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

# КАРАРЫ

**01 ноябрь 2024 ел** **№4**

**Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Урта Бирәзә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Наласа авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Урта Бирәзә авылында Урта Бирәзә авылы, Татарстан урамы, 90 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 21 ноябренә 11 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. «Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 1000 сум тәшкил иткән балачактан инвалидлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның 500 сум күләмендә үзара салым

кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (универсаль спорт мәйданчыгы -2 өчен киртә төзү һәм инвентарь сатып алу);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләр) төзекләндерү (күл территориясен тигезләү һәм чистарту, янәшәдәге территорияне яшелләндерү һәм кече архитектура формаларын урнаштыру - ял итү өчен эскәмияләр, чүп савытлары)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

3. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Урта Бирәзә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Наласа авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендында ТР, Арча районы, Урта Бирәзә авылы, Татарстан урамы, 90 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Наласа авыл җирлеге»
башлык урынбасары: И.Р. Тухфатуллин